**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛЫКЛЫ-ЧУКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422655, с.Балыклы-Чукаево, ул. Центральная, дом 9**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛЫКЛЫ ЧҮКӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**422655, Балыклы Чүкәй авылы, Үзәк урам, 9 йорт**

**Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, e-mail:blc.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 18 апреле Балыклы Чүкәй ав. № 7

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерүне һәм аларның реестрын алып баруны тәртипкә салу турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1998 елның 24 июнендәге "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы "Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында" 1039 номерлы Карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга:

1.1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты белән килештерү турында гариза бирүчеләр өчен 1 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Гариза формасын;

1.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) турында мәгълүматларны реестрга кертү өчен 2 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Гариза формасын;

1.3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарының (мәйданчыкларының) 3 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Реестры формасын.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәэмин итәргә:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрын формалаштыруны һәм аны кәгазь йөрткечтә һәм электрон рәвештә, анда каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарының (мәйданчыкларының) урнашу урыннары, каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары, каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарының (мәйданчыкларының) милекчеләре, каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарында (мәйданчыкларында) ташлана (өеп куела) торган каты коммуналь калдыкларның барлыкка килү чыганаклары турындагы мәгълүматларны күрсәтеп, алып баруны;
- каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) булдыру турында гаризалар карауны.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керүен һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таралуын билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы Чүкәй авылы, Үзәк урам, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урам, 23А йорт; Керәшен Казысы авылы,Титов урамы,11Б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнән җаваплылыкны калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге башлыгы А.М.Нуретдинова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛЫКЛЫ-ЧУКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ